# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең Мортыш-Тамак торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

№ 2 30 ноябрь 2025

2025 елның 20 мартында кабул ителгән № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45 нче, 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Мортыш-Тамак торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Мортыш-Тамак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВО зонасында катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, СВО зонасында катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

*1) Авыл җирлеге чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Мортыш-Тамак авылына керү юлына вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).*

3. Әлеге карарны Кадрәк авыл җирлегенең мәгълүмат такталарында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Кадрәк авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Нәбиуллин